ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 10-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, Р.У. Әхмәтов, О.М. Воронова, А.И. Зыятдинов, А.С. Созинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 10-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 9 октябре
№ 86-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М. Захарова,
Р.У. Әхмәтов,
О.М. Воронова,
А.И. Зыятдинов,
А.С. Созинов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш) № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тиешле финанс елына һәм план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы нигезендә Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектына Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән авырулар вакытында медицина ярдәме һәм Россия Федерациясенең тиешле субъекты территориясендә фактта күрсәтелгән паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясенең тиешле субъекты арасында төзелә торган чыгымнарны каплау мәсьәләсен ике яклы җайга салуны үз эченә алган регионара килешү нигезендә

каплый. Мондый килешүне төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

2023 елның 28 декабрендәге 2353 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасының V бүлеге нигезләмәсе нигезендә территориясендә граждан яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе субъекты тарафыннан әлеге Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә территориясендә гражданга фактта медицина ярдәме күрсәтелгән Россия Федерациясе субъектына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән авырулар вакытында медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплау күздә тотыла. Чыгымнарны каплау Россия Федерациясе субъектлары арасында төзелә торган һәм чыгымнарны каплау мәсьәләсен ике яклы җайга салуны күздә тота торган регионара килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына чыгымнарны каплау мәсьәләсен ике яклы җайга салуны үз эченә алган мондый килешүне төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә дигән норма өстәү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән авырулар вакытында медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауны ике яклы җайга салуны үз эченә алган регионара килешүләр төзү тәртибен эшләүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.